РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_08_» ___06___ 2026 ел №596

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су түгү өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында»гы 07.12.2011 № 416-ФЗ Федераль законы, «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы 27.07.2010 № 190-ФЗ Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә өзлексез җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне, су агызуны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасының «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесенә (ОГРН 1051641034807, ИНН 1660079256) хокук бирергә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләүче оешма статусы белән тәэмин итү;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының түбәндәге торак пунктлары территориясендә су белән тәэмин итү һәм су түгү өлкәсендә гарантияләүче оешма статусы белән: Әбсәләм авылы, Димтамак авылы, Ак Юл авылы, Алабакүл авылы, Тарлау авылы, Урыссу штб, Байлар авылы, Ютазы авылы, Ык авылы, Ютазы кымыз дәваханәсе бистәсе.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су агызу өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында" 29.05.2026 ел, № 583 карарын үз көчен югалткан дип танырга..

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 15 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Е.С. Огнева
2-42-19